РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
СОВЕТ ВЕРХНЕЛАЩИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮГАРЫ ЛАШЧЫ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«22» декабрь 2020ел № 1-8

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районы Югары Лашчы авыл җирлегендә
муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы һәм муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлеге Советының 2019 елның 25 февралендәге 3-1 номерлы карары белән расланган (12.02.2020 ел № 81-1, 20.10.2020 ел № 1-4, 23.11.2020 ел 1-6 номерлы карар редакциясендә), Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (алга таба текст буенча – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 25 бүлек:

25.4 пунктының 2 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә

«2) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе, шулай ук кирәк булганда муниципаль хезмәтнең стажын (2020 елның 1 гыйнварына кадәр чорлар өчен) һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 25.06.2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы статьясында күрсәтелгән башка документларның күчермәләре;».

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам

Буа муниципаль районы Югары Лашчы
авыл җирлеге башлыгы Г.Х. Усманова